КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 октябрь г.Казань № 898

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә һәм чиктәш территорияләрдә сәнәгать-җитештерү төрендәге махсус икътисадый зонаны планлаштыру проектын раслау турында

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү төрендәге махсус икътисадый зона территориясен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $9^1$ өлеше нигезендә шәһәр төзү документлары белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Kararga теркәлгән Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә һәм чиктәш территорияләрдә сәнәгать-җитештерү төрендәге махсус икътисадый зонаны планлаштыру проектын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә һәм чиктәш территорияләрдә сәнәгать-җитештерү төрендәге махсус икътисадый зонаны планлаштыру проектын раслау турында» 2015 ел, 09 июль, 504 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Премьер–министр
Республики Татарстан А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 3 октябрь, 898 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә һәм чиктәш территорияләрдә сәнәгать-җитештерү төрендәге махсус икътисадый зонаны планлаштыру проекты**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә һәм чиктәш территорияләрдә сәнәгать-җитештерү төрендәге махсус икътисадый зонаны планлаштыру проекты 4 томнан гыйбарәт:

1 том «Планлаштыру проекты нигезләмәләре»;

2 том «График материаллар»;

3 том «Аңлатма»;

4 том «График материаллар».

___